
Бергәләп өйрәник



# Күз

## Әти-әниләр өчен к ярдәмлек

(5-6 яшь)

**Көз турында сынамышлар.**

а) Миләш күп булган елны көз озын һәм яңгырлы була.

б) Сентябрьдә алма, ә октябрьда кәбестә исе аңкый.

в) Агачтан яфрак сирәк коелса, кыш салкын була.

**Табышмак:**

Һәр көн диярлек

Елап яшь коя.

Килгән кошларны

Көньякка куа. (Көз).

**Үстерешле уен «Сүзләр ясау».**

Мәсәлән: кызыл – кып-кызыл, яшел – яшькелт, ямь- яшел,

сары – сап-сары һ.б.

**Җырлы уен «Көз һәм яңгыр».**

Балалар бер якка тезелеп басалар, алар каршында .

Көз басып тора

Балалар: Исәнме, Көз, алтын көз!

Безне сагынып килдеңме?

Агачларга, куакларга

Сары чуклар элдеңме?

Көз: Саумы, нәни дусларым!

Сезне сагынып килдем мин,

Сезгә аяз көннәрдә

Көз балаларны куа башлый. Берничә бала

тотылгач, рольләр

алышына һәм уен шулай дәвам итә.

**Көз.**

Алтын-сары
Яфракларны
Җилләр саный.
Иртә-кичен
Суык бабай
Бармак яный.

"Ник гомергә
Килми икән
Шушы язлар?!"
Дигән кебек
Моңсу гына
Китә казлар.
Әнә инде

Юлга чыккан
Торналар да…
Бер үк сүзне
Кабатлыйлар,
Гүя, бар да:
— Суык бабай
Арттан җитеп
Харап булмыйк,
Оча торыйк,
Бара торыйк,
Тор-рыйк,
Тор-рыйк!